СОВЕТ УРМАНЧЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Ленина, д.5, п.Зверосовхоза,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422186

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ УРМАНЧЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Ленин ур., 5 нче йорт, Җәнлек совхозы поселогы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422186

тел.(факс): (85563) 2-12-50; e-mail: Urman.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Карар
№4-40

Решение
“20” ноябрь, 2018ел.

2018 елның 18 ноябрендә үткәрелгән
җирле референдумда кабул ителгән карарны теркәү турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 12.06.2002 ел, № 67-ФЗ Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 22, 56 статьялары, «җирле референдум турында» 2004 елның 24 апрелендәге 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы нигезендә, 2018 елнын 18 ноябрендә үткәрелгән җирле референдум нәтиҗәләре нигезендә бирелгән сорауга:

«2019 елда Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Урманчы авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган, 1 һәм 2 төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләр ветераннары, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, күп балалы гаиләләрдән, көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына вакытлы хезмәткә чакырылган гражданнардан кала, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә 300 сум күләмендә үзара салым кертергә риза буласызмы?:

**1.Җирлек чикләрендә су белән тәэмин итү, ташландык суларны агызу:** Торак пунктта су алу башнясы өчен су насосы сатып алу.Яңа пос., Кама урман хуҗалыгы т. п. ; Җәнлек совхозы п. п., Урманчы т. п., Кама урман хуҗалыгы – 2 шт., Новый П. т., Сотово т. п., чишмәләрне төзекләндерү

**2.Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге**:
Урманчы авыл җирлеге торак пунктларында җирле әһәмияттәге юлларны грейдерлау һәм кардан чистарту.

«ӘЙЕ» «ЮК»

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Урманчы авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы территориаль сайлау комиссиясенең 2018 елның 19 ноябрендәге 925 номерлы «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Урманчы авыл җирлеге территориясендә җирле референдум нәтиҗәләре турында»карарын теркәргә.

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районының mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

Мамадыш муниципаль районы
Урманчы авыл җирлеге башлыгы,
Совет рәисе А.Я.Ильин